ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУРАКАЙ

АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423746, Чуракай авылы, Совет ур., 69 йорт

СОВЕТ ЧУРАКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423746, село Чуракаево, ул. Советская, дом 69

КАРАР

РЕШЕНИЕ

от 28.11.2019 г.

№ 31

**Чуракай авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 28.11.2019 елгы. гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә Чуракай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Чуракай авыл җирлеге территориясендә 2020 нче елда, 1 нче төркем инвалидларыннан,кондезге булектэ укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.:

- авыл эчендәге машиналар йори торган юлларның тозеклеге, юлларны ремонтлау һәм карап тоту (грейдерлау,кардан чистарту);

- Чуракай, Иске Әгъбәз авылларында урам утлары чыгымнарын тәэмин иту;

-Чуракай авылында су торбаларын алыштыру, су чыганакларын рэсмилэштеру;

-Чуракай, Иске Әгъбәз авылы зиярат җирләрен рәсмиләштерү

- Зиярат ихаталарын коймалап бетерүне хәл итү

2. Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Чуракай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Чуракай Советы Башлыгы